ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

2021 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. 2021 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планын нигездә кабул итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон чыгару инициативасы хокукына ия субъектлар 2021 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планына искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне 2020 елның 8 декабренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетына кертергә тиеш.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты, закон чыгару инициативасы хокукына ия субъектлардан кергән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алып, 2021 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планын 2020 елның 20 декабренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2020 елның 26 ноябре
№ 719-VI ДС

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советының
2020 елның 26 ноябрендәге
719-VI ДС номерлы
карарына кушымта

**2021 елга**
**Татарстан Республикасы Дәүләт Советында**
**закон проекты эшенең якынча планы**

| № т/б | Проектның исеме | Закон чыгару инициативасы хокукы субъекты | Проектны Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тапшыру вакыты |
|---|---|---|---|
| | **1. Дәүләт корылышы** | | |
| 1 | Россия Федерациясе Конституциясенә төзәтмәләр хакында «Гавами хакимиятне оештыруның һәм аның эшчәнлегенең аерым мәсьәләләрен җайга салуны камилләштерү турында» 2020 елның 14 мартындагы 1-ФКЗ номерлы Россия Федерациясе Законын гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән Татарстан Республикасы законнары проектлары | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары | Ел дәвамында |
| 2 | «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының | III квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасына кандидатларны өстәмә җыю процедурасын билгеләү өлешендә) | Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты | |
| 3 | «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны бозган өчен административ җаваплылыкны төгәлләштерү өлешендә) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты | IV квартал |
| 4 | «Татарстан Республикасында дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен квалификация таләпләренә туры килүгә белемнәрне бәяләү үткәрү тәртибен камилләштерү өлешендә) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты | IV квартал |
| 5 | «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы «Биектау авыл җирлеге» һәм «Красносельский авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләренең чикләрен үзгәртү турында» Татарстан Республикасы законы проекты (яңа муниципаль берәмлек барлыкка килүгә бәйле рәвештә) | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы | IV квартал |
| 6 | «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр | Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе | IV квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты (аерым нормаларны «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукларының төп гарантияләре хакында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль закондагы үзгәрешләргә туры китерү өлешендә) | | |
| 7 | «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (муниципаль норматив хокукый актлар проектларына җайга салу йогынтысын бәяләү, шулай ук муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза үткәрү мәҗбүри булган муниципаль районнар һәм шәһәр округлары исемлеген төгәлләштерү өлешендә) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты | IV квартал |
| 8 | «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламенты турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2004 елның 26 февралендәге 2632 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты (Татарстан Республикасы законнарына туры китерү өлешендә) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Ш.Ш. Яһудин | IV квартал |
| **2. Икътисадый сәясәт** | | | |
| 9 | «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр | Татарстан Республикасы | I квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты (арендага торглар үткәрелмичә генә бирелә торган җир кишәрлекләрендә гамәлгә ашырыла торган масштаблы инвестиция проектларының сыйфат һәм сан критерийлары күрсәткечләрен беркетү өлешендә Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертүгә юнәлдерелгән) | Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты | |
| 10 | «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты (федераль законнарга туры китерү өлешендә) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты | I квартал |
| 11 | «Татарстан Республикасы Экология кодексының 89 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты (федераль законнарга туры китерү өлешендә) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.Г. Хәбибрахманов | I квартал |
| 12 | «2020 елгы Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында» Татарстан Республикасы законы проекты (Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $97^4$ статьясы нигезендә) | Татарстан Республикасы Президенты | II квартал |
| 13 | «2020 елгы Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше турында» Татарстан Республикасы законы проекты (Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $97^6$ статьясы нигезендә) | Татарстан Республикасы Президенты | II квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 14 | «Татарстан Республикасында цифрлы инновацияләр өлкәсендә эксперименталь хокук режимнары турында» Татарстан Республикасы законы проекты («Россия Федерациясендә цифрлы инновацияләр өлкәсендә эксперименталь хокук режимнары турында» 2020 елның 31 июлендәге 258-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе субъекты законнары белән тиешле территориядә эксперименталь хокук режимы урнаштыру мөмкинлеген гамәлгә ашыру. Федераль закон цифрлы инновацияләр өлкәсендә эксперименталь хокук режимнарының максатларын һәм принципларын, эксперименталь хокук режимнарында катнашучылар даирәсен билгели, шулай ук бу режимнарны урнаштыру һәм гамәлгә ашыру белән бәйле мөнәсәбәтләрне җайга сала) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты | II квартал |
| 15 | «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы законы проекты (Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 61 статьясы нигезендә) | Татарстан Республикасы Президенты | IV квартал |
| 16 | «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы законы проекты (Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 61 статьясы нигезендә) | Татарстан Республикасы Президенты | IV квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | **3. Социаль сәясәт** | | |
| 17 | «2022 елга Татарстан Республикасында хезмәт базары үзенчәлекләрен чагылдыра торган региональ коэффициентны билгеләү турында» Татарстан Республикасы законы проекты (патент нигезендә физик һәм юридик затларда хезмәт эшчәнлеген наем буенча гамәлгә ашыручы чит ил гражданнарының физик затлар керемнәренә салым буенча теркәлгән түләүләр күләмен индексацияләү максатларында Россия Федерациясе субъекты законы белән тиешле календарь ел өчен хезмәт базарының региональ үзенчәлекләрен чагылдыра торган коэффициентны билгеләү максатында) | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты | III квартал |
| 18 | «Пенсиягә федераль социаль өстәмә күләмен билгеләү өчен Татарстан Республикасында 2022 елга пенсионерның яшәү минимумы күләмен билгеләү турында» Татарстан Республикасы законы проекты («Россия Федерациясендә яшәү минимумы турында» 1997 елның 24 октябрендәге 134-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясындагы 4 пункты нигезендә) | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты | III квартал |
| 19 | «2022 елга Татарстан Республикасы гомуми белем бирү һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты | III квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» Татарстан Республикасы законы проекты («Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законның $26^3$ статьясы һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы нигезендә) | | |
| 20 | «2022 елга Татарстан Республикасында мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» Татарстан Республикасы законы проекты («Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законның $26^3$ статьясы һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы нигезендә) | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты | III квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 21 | «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты («Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына гражданнарның социаль ярдәм чаралары алуга хокуклары, шулай ук аларны билгеләү һәм бирү шартлары турында нигезләмә өстәү максатында) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты | IV квартал |
| 22 | «Бер яшь ярымнан өч яшькә кадәрге балаларның әниләренә бала караган өчен айлык түләүләр турында» Татарстан Республикасы законы проекты (баланы балалар бакчасының ясле төркеменә, мондый төркемнәрнең җитәрлек булмавына бәйле рәвештә, урнаштырып булмауны исәпкә алып, бер яшь ярымнан өч яшькә кадәрге балаларның бала карау ялында булган әниләренә бала караган өчен региональ минималь хезмәт хакы күләмендәге айлык түләүләрне кире кайтару максатында) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты О.М. Воронова | IV квартал |
| **4. Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативалары** | | | |
| 23 | «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм | I квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | законга үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проекты (авыр йөк транспорты чараларына авырлык һәм күләм контролен гамәлгә ашыру тәртибен төгәлләштерү максатында) | инфраструктура үсеше комитеты | |
| 24 | «Электр энергетикасы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проекты (энергия җибәрү эшчәнлеген лицензияләүне бетерү максатында) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Р.Х. Сөләйманов | I квартал |
| 25 | «Конкуренцияне яклау турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проекты (мәгълүмат тапшыру срокларын үзгәртү өлешендә) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Р.Х. Сөләйманов | II квартал |
| 26 | «Россия Федерациясе прокуратурасы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проекты (мәгълүмат тапшыру срокларын үзгәртү өлешендә) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Р.Х. Сөләйманов | II квартал |
| 27 | «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проекты (мәгълүмат тапшыру срокларын үзгәртү өлешендә) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Р.Х. Сөләйманов | II квартал |
| 28 | «Россия Федерациясендә кулланучылар кооперациясе (кулланучылар җәмгыятьләре, аларның берлекләре) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты | II квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проекты (кулланучылар җәмгыятенә керү, ихтыярый чыгу, идарә органнарына тавыш бирү фактларын исәпкә алу, шулай ук пайчыларның электрон реестрын алып бару өчен автоматлаштырылган программа комплексыннан файдалану мөмкинлеге өлешендә) | А.Р. Нәбиева | |
| 29 | «Бөлгенлек (банкротлык) турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проекты (127-ФЗ номерлы Федераль законга агымдагы бурычлар буенча кредитор конкурс эше барышы турындагы һәм бурычлы затның акчаларыннан әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда файдалану хакындагы хисаплар белән танышу хокукы турында нигезләмә өстәү максатыннан) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Р.Х. Сөләйманов | III квартал |
| 30 | «Россия Федерациясендә матди булмаган мәдәни ядкарьләр турында» федераль закон проекты (Россия халыкларының матди булмаган мәдәни ядкарьләрен ачыклау, саклап калу, өйрәнү, файдалану һәм аларны популярлаштыру өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне законнар белән җайга салу максатында) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты | IV квартал |